**СОВЕТ**
**СТАРОЧЕКАЛДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
**АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ИСКЕ ЧЕКАЛДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2026 Иске Чекалда авылы № 11-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Советының 16.05.2022 елның 21-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31 июлендәге 248-ФЗ номерлы, «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм индивидуаль эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль законга һәм «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» Федераль законның 29 һәм 65 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 29 декабрендәге 548-ФЗ номерлы Федераль законга үзгәрешләр кертү турында Федераль законнар нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Иске Чекалда авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру турында» Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлеге Советының 16.05.2022 елның 21-1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.7.1 пунктының 5 пунктчасында «аларның вәкилләре,» сүзләреннән соң «үз-үзен җайга салучы оешма вәкилләре, әгәр контрольдә тотыла торган зат өчен үз-үзен җайга салучы оешмада мәҗбүри әгъзалык каралган булса,» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Чекалда авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендында халыкка чыгарырга, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (https://agryz.tatarstan.ru) һәм

Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru).

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ш.К.Галимов